**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ LIII УТЫРЫШЫ**

**КАРАР №85**

*Симәк авылы* 25 *февраль 2025 ел.*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның «26» ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокуратурасының 2025 елның 27 гыйнварындагы 02-08-01-2025 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның «26» ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм аларның һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;»;

1.2 . 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләрендә файдаланылмый торган «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган, моңа һәр җир кишәрлегенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләре керми».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкк җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симә авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар РФ Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мөслим районы
Симәк авыл җирлеге башлыгы: Садертдинов Р.Ә.